| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

01.10.2019 г. Казань № 3087-р

**Татарстан Республикасының су фонды, урман фонды җирләрен, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләрен дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында**

«Дәүләт кадастр бәясе турында» 2016 елның 3 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль законына туры китереп, «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт кадастр бәяләвен «Дәүләт кадастр бәясе турында» 2016 елның 3 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә үткәрүгә күчү датасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.08.2017 № 576 карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасының су фонды, урман фонды җирләрен, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләрен дәүләт кадастр бәяләвенең 2019 елның 1 январена кадәрге тәкъдим ителгән нәтиҗәләрен (алга таба – Нәтиҗәләр) расларга.
2. Дәүләт теркәү, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Нәтиҗәләрне тиешле тәртиптә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертергә тәкъдим итергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары вазыйфаларын башкаручы Т.Ф.Хөснетдиновка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**